*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*



# Чишмә башы

*Май, 2025 ел*



***Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар***

**Беренче май белән дуслар!**

Беренче Май килде җиргә,
Якты нурга күмелеп.
Төрле төскә керде җиһан
Матурлыкка төренеп.

Кулларында төрле шарлар,
Мәйдан тулы балалар.
Шау-шу килеп көлә-көлә,
Бәйрәмгә куаналар.

Зәңгәр күктә уйнап оча,
Аклы, күкле күгәрчен.
Кояшлы матур көннәргә
Куанадыр, күрәсең.

Бакчадагы агачлар да
Матур күлмәген киеп
Каршы алды Май бәйрәмен
Шау чәчәккә күмелеп.

Җырлап килде яз бәйрәме,
Яңа хисләр уятып.
Дулкынланып типте йөрәк
Өмет белән куанып.

Гиматдинова Л.Ф.





## «ЭКО ЯЗ 2025»

## 5 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ « Тынычлык, Хезмәт, Май »

ЭКО ЯЗ бәйгесенең бу атнасы территорияне җыештыру һәм төзекләндерүгә юнәлтелгән һәм 1 май бәйрәменә багышланган. Территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү табигать тирәлеге материалында акыл, әхлакый, эстетик һәм физик тәрбия бирергә, кызыксынучанлыкны, гаҗәпләнү сәләтен үстерергә ярдәм итә. Бу безнең матур дөньяда яшәү теләге, чөнки тәртип кешедә дә, аның тирәсендә дә булырга тиеш. Тәрбияләнүчеләребез, абый-энеләрен, апа-сеңелләрен һәм бөтен гаиләләрен җәлеп итеп, йорт яны участокларын җыештыруны һәм төзекләндерүне дәвам иттеләр.








## 5 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ «Үзгәртү»

«ЭКО ЯЗ» республика бәйгесенең экологик марафоны кысаларында балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр әти-әниләр белән бергә «Үзгәртү» акциясендә актив катнаштылар. Бу акция кысаларында чишмәләр территориясе чистартылды














## 7 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ



## «Хайваннарны  кайгырту»



2025 елның 12 маеннан «ЭКО ЯЗ-2025» экологик марафонының 7 нче атнасы башланып китте. Ул «Хайваннарны кайгырту» исеме астында уза . Атна дәвамында Наласа балалар бакчасында балалар белән тематик әңгәмәләр үткәрелде, балалар хайваннар турында иллюстрацияләр карадылар, әкиятләр тыңладылар, табышмаклар чиштеләр, дидактик һәм  хәрәкәтле уеннар  уйнадылар, хайваннар турында мультфильмнар карадылар. Әйдәгез, бергәләп кече туганнарыбыз турында кайгыртыйк. Бу безнең ярдәмгә һәм игътибарга мохтаҗ хайваннар өчен файдалы нәрсә эшләү өчен менә дигән мөмкинлек. Хайваннарны яклауга багышланган акцияләргә һәм чараларга кушылыгыз. Бергәләп без дөньяны алар өчен яхшырак итә алабыз.
















## 8 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ  «Чиста су»



#ЭКО ЯЗ - 2025 республика акциянең сигезенче  атнасы «Чиста су» девизы  астында уза. Авыллардагы кечкенә елгаларның яр буе территорияләрен чүп-чардан чистарту мөһим бурыч булып тора, аның кайбер мөһим сәбәпләре бар. Зур һәм кечкенә елгалар планетада иң мөһим табигый ресурсларның берсе булып тора. Алар  авыл хуҗалыгы, промышленность һәм тереклек эшчәнлегенең башка өлкәләрен  төче су белән тәэмин итәләр. Әгәр ярларны вакытында чистартмасаң, бу суның пычрануына һәм аның сыйфатының начараюына китерергә мөмкин. Яр буе территориясен җыештыру, елганың биосферасын  сәламәт хәлдә тотарга ярдәм итә.

















## *«Бөек Җиңү көне белән!»*

7 май көнне, Бөек Җиңүнең 80 еллыгы алдыннан Наласа мәдәният йортында, Арча шәһәренең өлкәннәр һәм инвалидлар интернат-йорты, Наласа «Балачак» балалар бакчасы, китапханә һәм мәдәният йорты белән берлектә Җиңүнең 80 еллыгына багышланган чара узды. Чара программасына Җиңү бәйрәме, тынычлык, солдатлар турында җырлар, биюләр, сугыш турында шигырьләр, Ватанны саклаучыларның үлемсез батырлыгы турында җырлар кертелде. «Билгесез солдат» һәйкәленә чәчәкләр куелды, һәлак булучылар бер минут тынлык белән искә алынды.










## *«Җиңү тәрәзәләре»*







## *Балаларның, тәрбиячеләрнең уңышлары*

























## *«Бакчабызда кунаклар»*

14 нче май көнне Наласа авыл җирлегендә семинар булды. Арча районының башкарма комитеты җитәкчесе Алмаз Гаптраупович Хисаметдинов һәм бик күп кунаклар килде. Алар бакча тормышы эшчәнлеге белән таныштылар. Бакча хезмәткәрләренә эшләрендә уңышлар теләделәр һәм балаларга матур теләкләрен җиткерделәр. Бик канәгать булып киттеләр.







## *«Ата-аналар җыелышы»*

Бакчабызда «Уку елына нәтиҗә ясау »темасына багышланган ата-аналар җыелышы булып узды. Җыелышта түбәндәге мәсьәләләр каралды:

- 2024-2025 елгы уку елына нәтиҗә ясау;
- балаларның мәктәпкә әзерлеген анализлау;
- «Без барыбыз да җәяүлеләр »темасына кинәшләр;
- җәйге сәламәтләндерү планы белән таныштыру һәм төрлеләр. Бакча мөдире Гафурова Эльмира Рашат кызы ата-аналарны балалар бакчасы тормышында актив катнашулары белән котлады, рәхмәт сүзләрен җиткерде. Килеп туган авырлыкларны һәрвакыт бергәләшеп чишеп булуы турында ассызыклады, сорауларга җаваплар бирелде.











## *«Әкият иленә сәяхәт»*

Май азагы һәрвакыт чыгарылыш кичәләре белән билгеләп үтелә. Балалар бакчасында чыгарылыш кичәсе-моңсу да, шатлыклы да: балалар бакча белән саубуллашалар, алда аларны «мәктәп»д ип аталган яңа тормыш көтә. Зал бизәлгән, әти-әниләр, кунаклар чакырылган, барысы да дулкынлана. Һәм менә бәйрәмчә киенгән балалар керә – бәйрәм башлана.

Бәйрәм «Әкият иленә сәяхәт» дип атала. Төрле әкият геройлары булып киенеп ,бакча хезмәткәрләре балаларга матур бәйрәм оештырдылар.Тамаша вакытында балалар үзләренең бакчада өйрәнгәннәрен күрсәттеләр - җырладылар, биеделәр, матур итеп шигырьләр сөйләделәр, табышмакларга җавап бирделәр, математик бурычларны чиштеләр. Өлкән иптәшләрен котларга нәниләр дә килгән иде. Балалар бакчасы мөдире Гафурова Эльмира Рашат кызы чыгарылыш төркем балаларына мәктәп тормышы дәвамында уңышлар, зур үрләргә ирешүләрен теләде һәм беренче документ – балалар бакчасын тәмамлау турында диплом тапшырды. Без дә чыгарылыш балаларын чын күнелдән котлыйбыз һәм киләчәктә укуларында уңышлар теләп калабыз.



















***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Гафурова Р.А., Хөсәенова Р.Н., Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары****: Шагиева А.К., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР, Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*